ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2020 ел Баулы шәһәре №81

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының
Ситуацион үзәген төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 2 октябрендәге 894 номерлы карары (2009 елның 26 ноябрендәге редакциядә) «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарында, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәгенә керүче оешмаларда эшләүче функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә типлаштырылган таләпләр стандартын һәм Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 906 нчы карары, кергән Распределенный ситуационный үзәге» нигезендә, Татарстан Республикасы ситуацион үзәкләр челтәрен булдыру буенча чараларны тормышка ашыру максатында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Ситуацион үзәген (алга таба – Ситуацион үзәк) төзергә.

2. Расларга:

- 1нче кушымта нигезендә Ситуацион үзәк турында нигезләмәне;

- 2нче кушымта нигезендә Ситуацион үзәк эшчәнлеге турында хисап формасын.

3. Билгеләргә:

3.1. Ситуацион үзәген булдыру һәм эшләтү өчен җаваплы зат һәм җитәкче итеп Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарын;

3.2. Мәгълүматны яклауны тәэмин итү һәм кулланучыларның мәгълүмати ресурслардан файдалана алуын оештыру өчен җаваплылык үзәге администраторы һәм үзәге - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы бүлеге (алга таба - мәгълүмати технологияләр бүлеге).

4. Мәгълүмати технологияләр бүлеге начальнигына:

- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати иминлек бүлеге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр әзерләргә һәм кертергә;

- Баулы муниципаль районы Башлыгына кварталга бер тапкыр булган ситуацион үзәк эшчәнлеге турында хисап тапшырырга.

5. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә ситуацион үзәктә эшләгәндә әлеге карарга таянып эш итәргә кирәк.

6. Таблица нигезендә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләренә мәгълүмати-аналитик модельләрне беркетергә:

Баулы муниципаль районы Башлыгына кварталга бер тапкыр ситуацион үзәк эшчәнлеге турында хисап тапшырырга.

5. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә ситуацион үзәктә эшләгәндә әлеге карарга таянып эш итәргә кирәк.

6. Таблица нигезендә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләренә мәгълүмати-аналитик модельләрне беркетергә:

| Мәгълүмати-аналитик модель исеме | Бүлекчәнең исеме (җаваплылык үзәге) |
|---|---|
| Тулаем территориаль продуктка кече эшмәкәрлек субъектларының йогынтысын бәяләү | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы |
| Җирле бюджетның өстәмә керемнә хезмәт хакын минималь хезмәт хакы күләменә җиткерүнең тәэсирен бәяләү | Баулы муниципаль районының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге, Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы |
| Кече бизнесның хуҗалык итүче субъектларына чагыштырма анализ | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге |
| Җирле бюджетка НДФЛ күчерү нормативын фаразлау | Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы |

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы Башкарма
Комитетының 2020 елның _________
____ номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының
ситуацион үзәге турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының ситуацион үзәгенең (алга таба – Ситуацион үзәк) бурычларын, функцияләрен һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар:

**мәгълүмати ресурс** - мәгълүмат, документлар, мәгълүмат системаларында документлар массивлары;

**мәгълүмати-аналитик модель** - башлангыч мәгълүмат нигезендә идарә итү күрсәткечләрен анализлау һәм формалаштыру алгоритмы;

**мәгълүмат системасы** - мәгълүмати технологияләрне эшкәртүне тәэмин итә торган мәгълүмат җыелмасы;

**мәгълүмат ресурслары реестры** - ситуацион үзәктә катнашучылар эшчәнлегендә кулланыла торган мәгълүмат ресурслары Исемлеге, мәгълүмат ресурсларын һәм аларның составларын исәпкә алу максатларында билгеләнгән тәртиптә формалаштырыла торган мәгълүмат ресурслары Исемлеге;

**мәгълүмати-аналитик модельләр реестры** - ситуацион үзәктә катнашучылар эшчәнлегендә кулланыла торган анализ алгоритмнары һәм идарә итү күрсәткечләре исемлеге, ул билгеләнгән тәртиптә башлангыч мәгълүмат нигезендә формалаша;

**ситуацион үзәк администраторы** - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге, ситуацион үзәк эшчәнлеген тәэмин итә;

**Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәге -** функциональ бәйсез, әмма мәгълүмати-хокукый мәгълүмат ресурслары һәм ситуацион үзәкләрнең мәгълүмати-аналитик модельләре белән бәйле, бердәм регламентлар (мәгълүмати һәм административ) буенча хезмәттәшлек итүче ситуацион үзәкләр җыелмасы);

**Ситуацион үзәкнең кулланучылары -** Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының функциональ бүлекчәләре, алар үз эшчәнлегендә мәгълүмати ресурслардан һәм ситуацион үзәк кысаларында тормышка ашырыла торган модельләштерү нәтиҗәләреннән файдаланалар.

1.3. Ситуацион үзәк мәгълүмати ресурсларның, мәгълүмати-аналитик системаларның, мәгълүмати системаларның һәм мәгълүматны эшкәртүнең программалы-техник чараларының оештыру-технологик комплексыннан гыйбарәт. Ул Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре өчен идарәче карарлар һәм мәгълүмати-аналитик материаллар проектларын әзерләүне тәэмин итү өчен билгеләнгән.

1.4. Ситуацион үзәк Татарстан Республикасының ситуацион үзәгенең бер элементы булып тора.

1.5. Ситуацион үзәк мәгълүмат ресурсларын, мәгълүмати-аналитик модельләрне, мәгълүмати системаларны үз эченә ала.

2. Ситуацион үзәкнең бурычлары

Ситуацион үзәкнең бурычлары булып тора:

2.1. Идарә итү карарлары проектларын һәм мәгълүмати-аналитик материаллар проектларын әзерләү өчен файдаланыла торган мәгълүмати-аналитик мәгълүматларны җыю, эшкәртү һәм анализлауны тәэмин итү;

2.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган регламент нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының оператив һәм стратегик характердагы бүтән карарларына мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

2.3. Баулы муниципаль районы башлыгы, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының профильле бүлекчәләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты запраслары буенча мәгълүмати, мәгълүмати-белешмә һәм мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү;

2.4. Баулы муниципаль районы тормыш-көнкүрешенең теге яки бу өлкәләрендә ситуацион һәм/яки имитацион модельләштерүне гамәлгә ашыру;

2.5. Ситуацион үзәктә эшкәртелә торган мәгълүматны саклау дәрәҗәсен тәэмин итү.

## 3. Ситуацион үзәк эшен оештыру

3.1. Ситуацион үзәкнең администраторы - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы бүлеге.

3.2. Ситуацион үзәк администраторы:

- ситуацион үзәк мәгълүматын саклау эшен башкара;

- түбәндәгеләрне контрольдә тота:

ситуацион үзәкне эксплуатацияләү;

агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү һәм ситуацион үзәкне үстерү;

- кулланучыларның Ситуацион үзәкнең мәгълүмати куркынычсызлыгы сәясәте нигезендә (ул Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән билгеләнә) Ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлеген бирә;

- Ситуацион үзәкнең мәгълүмат ресурслары реестрын һәм мәгълүмат-аналитик модельләрен үзәкләштереп алып баруны гамәлгә ашыра.

## 4. Ситуацион үзәктә катнашучыларның хокуклары

4.1. Ситуацион үзәк администраторы хокуклы:

- билгеләнгән тәртиптә Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының функциональ бүлекчәләреннән Ситуацион үзәк эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

- билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарында, Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында, башка учреждениеләрдә һәм оешмаларда Ситуацион үзәк исеменнән аның компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча эш итәргә.

4.2. Ситуацион үзәкнең кулланучылары - Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм аларның функциональ бүлекчәләре.

Ситуацион үзәк кулланучылары хокуклы:

- Баулы муниципаль районы башлыгы карары белән билгеләнә торган функциональ вазыйфаларга һәм аларның статусына карап, Ситуацион үзәкнең мәгълүмати-аналитик модельләренә һәм мәгълүмат системаларына тулы яки чикләнгән күләмдә кертелгән булырга;

- Ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурсларыннан билгеләнгән тәртиптә тематик җыелмалар алырга.

5. Мәгълүмат иминлеген тәэмин итү

Кулланучыларның Ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурсларыннан файдалана алуын оештыру барлык юнәлешләр буенча мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итүнең барлык таләпләрен һәм принципларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла:

- мәгълүматны мәгълүмати-техник йогынтылардан (компьютер атакларыннан саклау);

- мәгълүматны рөхсәтсез файдаланудан саклау;

- тиешле статуслы мәгълүмат ресурсларыннан чикләнгән файдалануны тәэмин итү;

- мәгълүмати ресурсларның резерв күчермәләрен алу.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты эшләре белән
идарә итүчечесе — Х.С. Мөгыйнов